# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Өчиле авылында халык җыены нәтиҗәләре турында**

**«16» ноябрь 2023 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,2023 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Өчиле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә түләү күләме 500 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- Өчиле авыл зиратында агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

Халык җыены беркетмәсе(йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 170 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 105 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 101 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 4 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Өчиле авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2.«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Өчиле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ

булган кешегә түләү күләме 500 сум тәшкил итә, көндезге формада укучы студентларга, 80 яшьтән узган гражданнарга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы?

- Өчиле авыл зиратында агач һәм куакларны санитар кисү һәм чыгару.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 йорты адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров